**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-899 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-890 номерлы һәм 2017 елның 26 декабрендәге ПУ-1168 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасына, V кисәктә «Татарстан Республикасының Украинадагы тулы вәкаләтле вәкиллеге» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Украинадагы тулы вәкаләтле вәкиллеге турында» 1994 елның 4 ноябрендәге ПУ-771 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 14 июнь
№ ПУ-426